ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

2023 ел, 17 май № 177

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Югары Акхуҗа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 3 һәм 4 өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2022 елның 21 февралендәге 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы "Югары Акхуҗа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: :

10 нчы маддәдә 8 нче пункт түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзац белән тулыландырырга:

"капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше күренешенә таләпләр;»;

20 нче маддәнең 15 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү проектын әзерләгәннән соң, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты Комиссия тәкъдим иткән проектны РФ Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясының 9 өлеше нигезендә тикшерә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш, төзекләндерү, торак-коммуналь хуҗалык һәм инфраструктура үсеше комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы башлыгы –
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы Советы Рәисе А. Г. Җиһаншин